Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Үзбәк торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлегенең Үзбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлеге Үзбәк торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлеге Үзбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы хәрби хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кар чистарту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зәй - Каратай авылы, Совет урамы, 99 йорт, 1 корылма, Үзбәк авылы, Луговая урамы, 2 йорт буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы М.И.Идиятова